КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 март г.Казань № 131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче; 2022 ел,

30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 3 март, 200 нче; 2023 ел, 16 октябрь, 1313 нче; 2024 ел, 1 февраль, 53 нче; 2024 ел, 1 март, 108 нче; 2024 ел, 16 март, 326 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, аңа түбәндәге эчтәлекле $6.5^{1}$ һәм $6.5^{2}$ пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә.

«$6.5^{1}$. Әлеге Нигезләмәнең 6.5 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок нигезле сәбәпләр аркасында узган булса, чыгарылганда бер тапкыр бирелә торган пособие, чыгарылганда кием комплекты, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында гариза тапшыру срогы гариза бирүче тарафыннан чыгарылганда бер тапкыр бирелә торган пособие, чыгарылганда кием комплекты, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү өчен үз вакытында Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүгә комачаулаган вакыйгалар беткән көннән соң килә торган көннән 30 календарь көн узганга кадәр, әлеге Нигезләмәнең $6.5^{2}$ пунктында күрсәтелгән нигезле сәбәпләр булуны раслау торган документларны теркәп, гариза биргәндә Үзәк бүлеге тарафыннан яңадан гамәлгә кертелергә тиеш.

$6.5^{2}$. Чыгарылганда бер тапкыр бирелә торган пособие, чыгарылганда кием комплекты, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында гариза тапшыру срогын яңадан гамәлгә кертү өчен нигезле сәбәпләр:

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге Нигезләмәнең 6.3 пунктында күрсәтелгән гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру;

әлеге Нигезләмәнең 6.3 пунктында күрсәтелгән гражданнар медицина оешмасында амбулатор яисә стационар дәвалануда булу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин